ЧӘРШӘМБЕ
21 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 42 (5842)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

БӨРТЕКЛЕ КУЛЬТУРАЛАР ЧӘЧҮНЕ ДӨРЕС ПЛАНЛАШТЫРЫРГА!

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты „Колхозларда бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру тәртибе“ һәм „Колхозларда бөртекле культураларның сортлы чәчүлекләрен планлаштыру турында“ карарлар кабул иттеләр. Бу карарлар иген уңышын күтәрү өчен, колхозларның җәмагат хуҗалыкларын тагын да үстерү өчен һәм колхозчылар массасының иҗади инициативасын көчәйтү өчен аеруча әһәмиятле чара булып торалар. Партия һәм хөкүмәт тарафыннан күрелгән бу чаралар иген уңышын күтәрүдә колхозларга тагын да киңрәк юл ачалар. Хәзер бөртекле культуралар чәчү планы, уҗым культуралары чәчүне аерым күрсәтеп, колхозларга елга бер тапкыр җиткерелә. Димәк, бу закон нигезендә һәрбер колхоз үзенең туфрак-климат һәм хуҗалык шартларын, чәчү әйләнешләрен нык исәпкә алып, бөртекле культуралар чәчүне планлаштыруны үзе хәл итә. Планлаштыру хокукы колхозларның үзләренә бирелде.

Колхозларның бөртекле культураларны чәчү планнары район башкарма комитетлары тарафыннан 25 нче февральгә расланып бетәргә тиеш.

Колхозда нинди культураны күпме чәчүне һәм нинди сорт орлык чәчүне планлаштыру—ул гаят җидди, гаят катлаулы, җаваплы эш. Аны тирәнтен уйлап, барлык тәҗрибәләрне исәпкә алып, бөтен иҗад көчен туплап эшләргә кирәк. Бу эшне хәл иткәндә авыл хуҗалыгы белгечләре, бай тәҗрибәгә ия булган карт колхозчылар, стахановчылар аеруча зур урын тоталар. Алар тарафыннан кертелгән һәрбер эшлекле тәкъдим, һәрбер файдалы киңәш, файдалы фикер искә алынырга, планда чагылырга тиеш.

Билгеле, бу мәсьәләдә колхозлар үз язмышларын үзләре хәл итәләр дип, аеруча әһәмиятле эшне үз агымына кую, анардан читтә тору зур ялгышлык булыр иде. Наркомзем һәм район җир бүлекләре, партия һәм совет органнары бөртекле культуралар чәчүне планлаштыруга оператив җитәкчелек итәргә, колхозларга зур булышлык күрсәтергә тиешләр.

Кайбер районнарда исә бу эшкә җитәкчелек итү һич тә канәгатьләнерлек түгел. Мәсәлән, Норлат райсоветы башкарма комитеты планнарны 60 колхозның 13 е буенча гына раслаган әле. Алексеевский районында „Кама“ һәм „Красное Прикамье“ колхозлары правлениеләре бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру тәртибе турында партия һәм хөкүмәт карарын колхозчыларга аңлатмаганнар. Бу факт аларның мондый җаваплы эшне канцеляриядә утырып „иҗад“ итү шикелле ялгыш юлга басканлыкларын, ә район оешмаларының читтә калуларын күрсәтә.

Бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру белән бергә, яхшы сыйфатлы чәчүлек орлык булдыру мәсьәләсе хәзерге көндә иң актуаль бурыч булып тора. Ләкин чәчүлек орлык туплау эше Татарстан колхозларында бик начар тора. Иртә чәчеләчәк башаклы культураларның чәчүлек орлыкларын туплау планы 75 процент чамасында гына үтәлгән әле. Шуның бары 70 проценты гына тазартылган. Колхозара алмашу Мөслим белән Дөбъяз районнарында гына ярыйсы бара.

Чәчүлек орлык ул беренче дәрәҗә әһәмиятле мәсьәлә. Аның турында кайгыртмау югары уңыш өчен көрәшне куркыныч астына кую дигән сүз. Шунлыктан, чәчүнең алтын фондын кирәк күләмдә һәм яхшы сыйфатлы итеп туплау бөтен кискенлеге белән куела һәм аның җаваплылыгы тулысынча район җитәкчеләренә, колхоз председательләренә йөкләнә!

Кайбер район һәм колхоз җитәкчеләрендә чәчүлек орлык буенча дәүләттән ссуда көтеп яту шикелле тенденцияләр бар. Мондый карашның урынсыз булуы турында менә берничә факт. Башта 10 мең центнерга заявка биргән Кайбыч районы, 8 мең центнер сораган Кызыл Йолдыз районы хәзер үз заявкаларыннан кире кайттылар. 7.410 центнер ссуда сораган Ворошилов районы, инде 3.000 центнер гына кирәк, ди. Үзендәге резервларны файдаланганда орлыкны тулысынча урында тупларга мөмкинлек бар.

Чәчүлек орлыкны районның үзендә табу буенча Теләче районы гүзәл үрнәк күрсәтә. Анда „Кызыл Янбулат“ колхозы үзе белән ярышучы „Төрек баш“ һәм „Чулпан №1“ колхозларына бурычка 600 центнер орлык бирергә карар иткән. „Кремль“ һәм „Мишә буе“ колхозлары да шундый ярдәм күрсәтәләр.

Бу гаят гүзәл башлангыч. Моны чәчүлек орлык җитешмәгән һәрбер районда оештырырга кирәк.

Моның өчен һәрбер колхозның фактагы положениесен ачык белергә, аңа дөрес анализ ясарга кирәк. Чәчүгә хәзерлектә һәм югары уңыш өчен көрәштә һәрбер колхоз үзен җаваплы сизсен өчен чәчүлек орлык табуда анардан инициатива күрсәтүен таләп итәргә кирәк.

Бөртекле культуралар чәчүне планлаштыру белән бергә, чәчүлек орлык туплау эше тулысынча тәмамланырга тиеш.

ШВЕЦИЯ ИЛЧЕСЕ В. АССАРССОН ӘФӘНДЕНЕҢ МОСКВАГА КИЛҮЕ

19 нчы февральдә Москвага Швециянең гадәттән тыш яңа илчесе һәм тулы хокуклы министре В. Ассарссон әфәнде килде.

Үзәк аэропортта В. Ассарссон әфәндене Наркоминделнең протоколлар бүлеге мөдире иптәш В. Н. Барков һәм Швеция миссиясенең Эйлер—Шельпин әфәнде җитәкчелегендәге составы каршы алдылар.

ТАСС ның юкка чыгаруы

1. Италиянең Стефани агентлыгының Истамбулдан хәбәр итүенә караганда, гүяки, „бер совет отряды Кавказда Төркия чиген үтеп чыккан“, „Төркия властьлары бу үтеп чыгуның сәбәпләрен белү өчен отряд җибәргәннәр“, ләкин „бәрелеш булмаган“.

Стефани агентлыгының бу хәбәре бөтенләе белән аның авторларының авыру фантазиясе нәтиҗәсе икәнлекне белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

2. Бельгиянең „Либр бельжик“ газетасы Юнайтед Пресс хәбәрчесенең хәбәрен басып чыгарган. Бу хәбәрдә, гүяки, „Руслар Финляндиядә Лолойка районында никель рудникларын көчле рәвештә эшләтә башлаганнар“ һәм „күп санлы эшчеләр шахталар төзүдә эшлиләр“ һ. б. диелә.

Юнайтед Пресснның бу хәбәренең чынлыкка һич тә туры килмәвен белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

19 нчы февральдә Карелия бугазында безнең һөҗүм уңышлы төстә киңәюдә дәвам итте. Безнең частьләр Бьоркадагы ныгытылган районны дошманнан чистартуны дәвам иттерделәр һәм **Юханнес** шәһәреннән 3 километр көнбатыштарак **Рион-Саари** атавын, **Юханнестан** 5 километр көньяк - көнбатыштарак **Ревон-Саари** атавын һәм диңгез буе тимер юлының **Ляхтеенмяки** һәм **Хумол Иоки** станцияләрен алдылар.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына актив сугыш хәрәкәтләре алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 14 самолеты бәреп төшерелде.

22 нче февраль, кич 6 сәгатьтә Зур Драма театры бинасында (Бауман урамы, 48) шәһәр партия, совет, комсомол, профсоюз активының һәм хәрби частьләрнең катнашы белән, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап, хезмәт ияләре депутатлары Казан Шәһәр Советының тантаналы сессиясе чакырыла.

ВКП(б) ның һәм ВЛКСМ ның өлкә һәм шәһәр комитетлары бюроларының членнары, СССР, РСФСР, Татарстан АССР Верховный Советларының һәм Казан Шәһәр Советының депутатлары үзләренең мандатлары белән керәләр.

Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты.

МТС һәм МТМ алдынгыларының РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр бирүче алдынгыларның һәм стахановчыларның республика почет тактасына ВКП(б) райкомнары һәм хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча кертеләләр:

28. Әтнә МТС ының 5 нче номерлы трактор бригадасы бригадиры иптәш **Ф. Гыйбадуллин**. Аның бригадасы тракторларга ремонт ясауны 1940 нчы елның 21 нче январена төгәлләде.

29. Чүпрәле МТС ының трактор бригадасы бригадирының ярдәмчесе иптәш **Н. П. Низамов**. Ул җитәкчелек итә торган бригада тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1939 нчы елның 15 нче декабренә төгәлләде.

30. Әтнә МТС ының 15 нче номерлы трактор бригадасы бригадиры иптәш **М. Нигмәтҗанов**. Аның бригадасында тракторларга ремонт ясау 1940 нчы елның 28 нче январена төгәлләнде

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЫНДА

21—22 нче февральдә Кызыл Армиянең XXII еллыгы хөрмәтенә Казан тимер юлында оборона көннәре үткәрелә. Барлык производство участкыларында Кызыл Армия турында беседалардан, докладлардан һәм лекцияләрдән тыш винтовка һәм пулемет өйрәнү буенча практик занятиеләр, ату ярышлары, противогаз киеп эшләү һәм башкалар үткәреләчәк.

Тимер юл идарәсендә 6 осоавиахимчы Вятские Поляныдан Казанга кадәр чаңгы чабышы үткәрәләр. Чабышка катнашучылар 5 пунктта тукталып, Кызыл Армиянең XXII еллыгы турында беседалар үткәрәчәкләр.

18 нче февральдә Казаннан Москвага эстафета поезды китте. Поездның барлык проводниклары—осоавиахимчылар. Юлда барганда алар пассажирлар арасында Кызыл Армия турында беседалар үткәрделәр һәм противогаз киеп эшләү үрнәкләрен күрсәттеләр. Казан тимер юлының башка станцияләреннән дә Осоавиахим эстафетасы поездлары җибәрелә.

ОБОРОНА ТҮГӘРӘКЛӘРЕ

Шөгер урта мәктәбендә Осоавиахимның башлангыч оешмасы данлыклы бәйрәмгә нык хәзерлек алып бара. Мәктәпнең 122 укучысы Осоавиахимда член булып торалар. ПВХО һәм Ворошиловча атучылар түгәрәкләре эшли. Бу түгәрәкләргә 274 кеше йөри.

10 нчы класс укучыларыннан 34 укучы ПВХО буенча инструкторлыкка хәзерләнәләр. Күптән түгел 35 укучы ГСО, 87 укучы ПВХО значокларына нормалар тапшырдылар. Топографияне өйрәнү һәм элемтәчеләр түгәрәкләренә укучылар зур кызыксыну белән йөриләр.

Х. Алеев.

ДАНЛЫКЛЫ ЕЛЛЫК ХӨРМӘТЕНӘ

22—23 нче февральдә Лаеш районының барлык колхозларында Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышланган тантаналы җыелышлар үткәреләчәк. ВКП(б) райкомы моның өчен 68 докладчы билгеләде. Докладчылар өчен семинар үткәрелде. 23 нче февральдә район үзәгендә чаңгы ярышы һәм „ГТО“ значогына чаңгы буенча масса күләмендә норма тапшырулар булачак.

Оборона йорты 18 нче февральдә Осоавиахимның башлангыч оешмаларының ату ярышларын үткәрде. 10 команда катнашкан бу ярышта беренче урынны саго заводының Осоавиахим командасы, икенче урынны ВКП(б) райкомы командасы алды.

Рождественский, Мансур, Державино һәм Емельяново авыл советларының барлык призывниклары оборона значокларына нормалар тапшырдылар.

МӘКТӘПТӘ КЫЗЫЛ АРМИЯ ПОЧМАГЫ

Апас урта мәктәбендә Кызыл Армия еллыгына хәзерлек һәм аны үткәрү буенча махсус комиссия эшли. Осоавиахимның мәктәп янындагы оешмасы инициативасы белән укучылар оборона значокларына нормалар тапшыралар.

Укучылар көче белән Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флотына багышланган концерт хәзерләнә. Чаңгы һәм шахмат ярышлары үткәрелә. Бәйрәмгә хәзерлек уңае белән мәктәп белән ярышучы Кильдураз авылы мәктәбенә 15 кешелек чаңгычылар командасы бара. Алар социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерәчәкләр.

Мәктәпнең пионер отрядлары альбомнар төзиләр. Кызыл Армия почмагы оештырыла. Кызыл Армиянең геройлары Чапаев, Щорс, Пархоменко һәм башкалар турында классларда беседалар үткәрелә.

А. Гарипов.

ЯҢА КИТАПЛАР

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына Татгосиздат күп кенә китаплар басып чыгара. Яңа чыгачак китаплар арасында Ананьевның „Перекоп өчен сугыш“, Бротманның „Полюс аша Америкага“, Вашенцевның „Каты буранда“, Антиповның „Дәһшәтле атакалар“, Герасимовның „Төньякта гражданнар сугышы“, Занегинның „Яш атучы“ дигән китаплары, Матэ Залканың „Хикәяләр“ исемле китабы һәм „СССР да гражданнар сугышы геройлары“ дигән җыентык бар.

ПРИЗЫВКА ХӘЗЕРЛЕК

Саба районының комсомолец допризывниклары һәм союздан тыш яшьләре призывка хәзерләнәләр. Призывникларның барсы да укый-яза беләләр. Аларның күпчелеге урта һәм югары белемле.

Күптән түгел допризывникларның район күләмендә җыелышы булды. Җыелышта призывны тагын да зуррак уңышлар белән каршылау турында йөкләмәләр алынды һәм Теләче районы допризывниклары социалистик ярышка чакырылды.

Г. Нәгыймов.

ПРОМКООПЕРАЦИЯ АРТЕЛЬЛӘРЕ ЗУР УҢЫШКА ИРЕШТЕЛӘР

Чистай шәһәрендә промкооперациянең „Путь“, „Искра“ һәм „Швейник“ артельләре Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына зур уңышлар белән киләләр. „Швейник“ артеле январь ае планын 139 процент, „Искра“ артеле 113 процент, „Путь“ артеле 112 процент итеп үтәде.

„Путь“ артеле стахановчыларыннан Шмелева, Коняшин, Ключникова, Мунин иптәшләр, „Швейник“ артеленнән Гурьянова, Архипова, Клюкина иптәшләр, „Искра“ артеленнән И. В. Ульянов, Малышев иптәшләр производство планнарын системалы рәвештә арттырып үтәп киләләр.

И. Матвеев.

Халык иҗады мастерлары эшенең күргәзмәсе

Татарстанның Халык Иҗады Йорты үзлекләреннән өйрәнгән художниклар, оста чигүчеләр, керамиклар, агачка һәм сөяккә рәсем ясаучылар эшләренең күргәзмәсен хәзерли. Күргәзмә Татарстан АССР ның XX еллыгына багышлана.

Күп кенә художниклар күргәзмәгә рәсемнәр һәм картиналар хәзерлиләр. Бухгалтер иптәш Пузраков (Лаеш районы) „Иптәш Сталин сайлау бюллетенен урнага сала“ дигән картинаны ясап бетерде. Художник иптәш Авдеев (Чистай шәһәре) „Җирдән мәңгелеккә файдалану акты“ һәм „Чәчәк атучы дала“ исемле картиналарын җибәрде. Алешин һәм Тырыгин иптәшләр (Казан) „Боз өстендәге сугыш“ һәм „Казан университетында яшь галимнең докторлык диссертациясе яклавы“ дигән картиналарны язалар.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 19 февраль. Рәсми рәвештә хәбәр итүләренә караганда, кичә „дошман башта көчле рәвештә миномет хәзерлеге алып барып, Мозельдән көнчыгыштарак французларның бер постына һөҗүм иткән, ләкин һөҗүм уңышсыз чыккан. Нидтан көнчыгышка таба безнең бер отрядыбыз дошман тозагына килеп эләккән һәм югалтуларга дучар булган. Рейн ярлары буендагы ныгытмалар арасында атышу бара“.

БРЮССЕЛЬ, 19 февраль. „Журналь“ газетасы бүгенге хәрби күзәтүендә болай дип хәбәр итә: „Вогезыдан көнбатышка таба французлар артиллериясе бу районда төрле фортификация эшләре алып баручы немец эшчеләреннән тора торган берничә отрядны таркаткан.

Франция авиациясе Германия өстендә, немецләр безнең линияләр өстендә тирән разведка очышлары үткәргәннәр“.

ЛОНДОН, 19 февраль. Англиянең 3.656 тонна авырлыктагы „Барон Эйсла“ пароходы Төньяк диңгездә һөҗүмгә очраган һәм баткан. 2 кеше һәлак булган.

Англиянең сугыш министрлегенең белдерүенә караганда, Англиянең 1.375 тонна авырлыктагы алтынчы эсминецы—„Дэринг“ батырылган. Экипаж составыннан бары 1 офицер һәм 4 матрос кына котылып калган. 9 офицер һәм 148 матрос хәбәрсез югалганнар. Аларны барсын да һәлак булган дип уйлыйлар. Шушы көннәрдә Швециянең дә „Осмед“ һәм „Лиана“ исемле 2 пароходы батырылган.

БЕРЛИН, 19 февраль. Германиянең информация бюросы сугыш башланганнан бирле Даниянең барлыгы 42 мең тонна авырлыктагы 18 сәүдә пароходы батырылды, дип хәбәр итә. (ТАСС).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ УҢЫШЛАРЫ ТУРЫНДА БОЛГАРИЯ МАТБУГАТЫ

СОФИЯ, 19 февраль. (ТАСС). Ак финнәргә каршы көрәштә совет гаскәрләренең уңышлары соңгы көннәрдә Болгария матбугатында киң яктыртыла башлады. Газеталар совет сугыш техникасының җимерелмәслек көчен һәм Кызыл Армия сугышчыларының һәм командирларының мораль дәрәҗәсе югары булуны күрсәтеп үтәләр.

„Утро“ газетасы болай дип яза: „Совет гаскәрләре үзләре алган позицияләрдә нык урнаштылар. Совет гаскәрләренең мораль хәле бик яхшы. Һава шартлары начар булуга карамастан, алар көндез дә, төнлә дә сугышалар“.

Газеталарның күпчелеге ак финнәрнең хәле бөтенләй ышанычсыз дип язалар. „Зора“ газетасының язуына караганда, Маннергейм Америка хәбәрчеләренә ак фин гаскәрләренең хәле бөтенләй ышанычсыз икәнлекне белдергән һәм гаять зур югалтулар турында әйткән.

БРЮССЕЛЬ, 19 февраль. (ТАСС). Голландиянең „Ньюве роттердамше курант“ газетасы, Финляндиядәге сугыш хәлләре турында болай дип яза: „Руслар тарафыннан флангларда ясалган комбинацияле атакалар финнәрне шул кадәр борчыдылар ки, алар моннан соң каршы тору мөмкинлегенә үзләре дә шикләнә башладылар. Русларның уңышы әле финнәрнең сугышта җиңелүе булып әверелмәгән. Ләкин, әгәр финнәр иң кыска вакыт эчендә материал һәм кешеләр белән ярдәм алмасалар, аларның җиңелүе реаль булып әвереләчәк“.

СТОКҺОЛЬМ, 19 февраль. (ТАСС). Кичәге кичке газеталар үзләренең Хельсинкидагы хәбәрчеләренең хәбәрләренә зур урын бирәләр.

„Нюа даглигт аллеханда“ газетасының хәбәрчесе болай дип яза: „Карелия фронтындагы хәл әле өметсез булмаса да, аны бүген бик җидди дип санарга мөмкин. Русларның куәтле һөҗүме һаман дәвам итә. Ләкин, икенче яктан, финнәр үзләренең каршылык күрсәтүләрен көчәйттеләр“.

СУГЫШ УТЫ КАБЫЗУЧЫЛАРНЫҢ НОРВЕГИЯДӘ ПРОВОКАЦИОН ЭШЕ

ОСЛО, 19 февраль. (ТАСС). Моннан бер ай элек Англиянең диңгез министре Черчилль речь сөйләп, Англия—Франция империалистларының сугышны киңәйтүгә, аерым алганда аны Скандинавиягә җәелдерүгә юнәлдерелгән чын планнарын ачып салган иде. Черчилль рече күп кенә нейтраль илләрдә, шул исәптән Норвегиядә дә зур ачу тудырды. Шуңа да карамастан, Англия—Франция блогы агентлары Черчилльнең янауларын тормышка ашыруга керештеләр. Алар Норвегиянең хәзер үк ак Финляндия ягында торып сугышка керешүен таләп итә башладылар. Социал-демократ Шарфенберг дигән ниндидер бер төрмә врачы күп урыннарда речьләр сөйләп, Норвегия хөкүмәтен „түзеп торуы“ өчен нык „тәнкыйть итә“. Норвегиянең Лондондагы элекке илчесе Фогт „Тиденс тейн“ газетасында Норвегия гаскәрләрен ак Финляндиягә ярдәмгә җибәрергә турыдан-туры чакырды. Норвегиядәге бу „активистларның“ җимерү эшенә социал-демократларның сатлык органы „Арбейдербладет“ газетасының редакторы Транмель җитәкчелек итә.

Шуның белән бергә нейтраль Норвегиягә Швеция реакциясе дә басым ясый. Синдлерның иярченнәре—Швеция полковнигы Братт һәм „профессор“ Анлунд күптән түгел генә чыгарылган китапларында „Скандинавия интересларыннан чыгып“ Швециянең генә түгел, бәлки Норвегиянең дә үзләренең гаскәрләрен Маннергеймга ярдәмгә җибәрүләрен таләп итәләр.

Сугыш уты кабызучыларның провокацион эшеннән Норвегия халкы арасында ризасызлык көчәя. Күп санлы җыелышларда Норвегия хезмәт ияләре үзләренең хөкүмәтләреннән ныклы нейтралитет саклауны таләп итәләр.

ШВЕЦИЯ КОРОЛЕ ХӨКҮМӘТНЕҢ КАРАРЫН ЯХШЫ ДИП ТАПТЫ

ЛОНДОН, 19 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Стокһольм хәбәрчесенең хәбәр итүенә караганда, Швеция короле Финляндиягә сугыш ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында хөкүмәт карарын яхшы дип тапкан.

ЛОНДОН КОНВЕНЦИЯСЕННӘН ГЕРМАНИЯНЕҢ БАШ ТАРТУЫ

ЛОНДОН, 19 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, су асты сугышы алып бару турында Лондон конвенциясенә Германия үзенең моннан соң бәйле түгеллеген белдергән. Белдерүдә, Англиянең Төньяк диңгездәге сәүдә карабларын коралландыруы—ул, су асты сугышы алып бару турында Лондон конвенциясен Англиянең бозуы, дип күрсәтелә. Белдерүдә болай диелә: „Хәзер Германиянең су асты көймәләре командирларына мондый коралланган сәүдә карабларын батырырга бойрык бирелде“.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин районында кытай гаскәрләре зур җиңүгә ирешкәннәр. Японнар Наньниннан нигездә инде кысрыклап чыгарылганнар. Японнарның баш командованиесе Циньчжоуга күчеп киткән. Японнарның төп көчләре дә шул юнәлештә чигенеп баралар. Кытайларның регуляр частьләре һәм партизаннар отрядлары японнарның чигенеп баручы гаскәрләрен зур югалтуларга дучар итеп, аларны мораль яктан таркаталар.

Үзәк Кытайда

Кытай гаскәрләре күп кенә уңайлы позицияләр алып, Сяошаньга якынлашып киләләр.

Цзянси провинциясенең төньяк өлешендә, Унин—Жуйчан шоссе юлында кытай партизаннары 15 нче февральдә 2 күперне шартлатып, японнарның юлын кискәннәр.

19 нчы февральдә Шанхай — Нанкин тимер юлының көнбатыш тармагында японнарның хәрби поезды кытайлар тарафыннан тимер юлга салынган минага килеп бәрелгән. Нәтиҗәдә 3 вагон бөтенләй җимерелгән. Үлүчеләр дә бар.

Төньяк Кытайда

Шаньси провинциясенең көньяк өлешендә кытай һәм япон частьләре арасында берничә вак бәрелешләр булган. Японнарның 100 дән артык кешеләре үтерелгән һәм яраланган.

***

„Дамэйбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 10 нчы февральдә кытай авиациясе японнарның Кантондагы хәрби объектларын бик нык бомбага тоткан. Берничә бомба японнарның сугыш караблары тора торган бухтага ташланган.

***

ЧУНЦИН, 19 февраль. (ТАСС). Гуандун провинциясенең хөкүмәт члены У Дисиньнең белдерүенә караганда, чигенеп баручы япон гаскәрләре тыныч халыкка карата аеруча катылык күрсәтәләр. 9 авыл бигрәк тә нык зарарланган. Японнар тыныч кешеләрдән 10 меңләп кешене үтергәннәр һәм 3 мең баш чамасы мөгезле эре терлекләрне алып киткәннәр. 2 меңнән артык йорт яндырылган. Күп кенә хәлләрдә крестьяннар японнарга үзләре отпор биргәннәр. Мәсәлән, Бацзянь авылы кешеләре японнарның һөҗүмнәрен өч тапкыр кире какканнар.

БАШЛАНГЫЧ ПАРТОЕШМАЛАРНЫҢ ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЛАРЫНДА

ОТЧЕТ ҺӘМ ТӘНКЫЙТ

„Урак һәм чүкеч“ заводы коммунистларының отчет-сайлау җыелышында партбюро секретаре иптәш Хомяков партоешманың 22 айлык эше турында доклад белән чыкты.

Партоешма отчет чорында шактый уңышларга ирешкән. Отчет чорында ВКП(б) сафларына кандидат итеп 25 һәм член итеп 16 кеше кабул ителгән. Ләкин, хатын-кызлар арасында политик тәрбия эшенең куелышы канәгатьләнерлек түгел. Алдынгы хатын-кызлардан партиягә 9 гына кеше кабул ителү факты моңа ачык мисаль.

Завод 1939 нчы елның производство планын валовой продукция буенча 107,3 процент итеп үтәүгә ирешкән. Коммунистларның күбесе производствода инициатива һәм үрнәк күрсәтәләр. Мәсәлән, коммунист иптәш Пухти көнлек эш нормасын 200—250 процент итеп үтәп килә. Иптәш Гайнеттинов һәр сменада 2—3 норма биреп баруга ирешә. Партбюро члены, стахановчы строгальщик иптәш Яруллин механика цехы эшчеләре арасында аңлату эше алып бара. Ул, яңа эшчеләргә техниканы үзләштерүдә булышлык күрсәтә.

Оешманың эшендә җитди кимчелекләре дә күп әле. Ул кимчелекләрнең берсе итеп, үткән елны ирешелгән уңышларның ныгытылмавын алырга кирәк. Январь аеның производство планы бары 64 процент, февраль аеның 15 көнлек планы 20 процент кына үтәлүе моны бик ачык күрсәтә.

Заводта политик-масса эше шактый йомшарган. Партбюроның кайбер членнары, завком җитәкчеләре цехларда аз булалар. Цехларда җыелышлар сирәк үткәрелә. Стена газеталары вактында чыгарылмый. Техминимум укулары начар оештырылган. Социалистик ярыш договорларының үтәлеше тикшерелми.

Партияле һәм партиясез кадрларны марксизм-ленинизм рухында тәрбияләү эше үз агымына куелган. Партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр бары 50 кеше исәпләнә. Шулардан коммунистлар 32 кеше. Аларның күпчелеге „Кыскача курс“ның әле III нче бүлеген генә өйрәнәләр.

Заводта партия-политик эшнең, кадрларны идея-ягыннан тәрбияләү эшенең йомшак куелуы нәтиҗәсендә, кайбер коммунистлар дисциплинасызлык күрсәтәләр.

Иптәш Хомяков докладын буенча 14 кеше чыгып сөйләде. Алар партоешманың уңышларын күрсәтү белән бергә, кимчелекләрнең тәнкыйт иттеләр.

Җыелыш партоешманың эшен канәгатьләнерлек дип тапты.

Г. Шаһиев.

Райком эшендәге җитешсезлекләрне ачып салалар

Биектау районы коммунистларының отчет-сайлау җыелышлары зур күтәренкелек белән үтә.

„Каменка“ санаториендәге отчет-сайлау җыелышында коммунистлар партоешма секретаре иптәш Логинованың эшен кискен рәвештә тәнкыйть иттеләр.

Санаторийнең партоешмасы 1939 нчы елда партия сафларына бер кеше дә кабул итмәгән. Партия членнарын политик тәрбияләү турында кайгыртмаган. Коммунист иптәш Христофоров ВКП(б) тарихын өйрәнүгә әле дә булса керешмәгән, ә партоешма секретаре бу турыда бер нәрсә дә белми.

Усады спирт заводындагы партоешманың отчет-сайлау җыелышында да шундый ук фактлар ачып салынды. Бу оешмада политик-тәрбия эшләренең торышы йомшак. Ә партоешма секретаре иптәш Комлев бу кимчелекләрне бетерү чараларын күрми.

Паново авылындагы коммунистлар партия поручениеләрен бик начар үтиләр. Ә оешма секретаре иптәш Баранов поручениеләрнең үтәлешен тикшермәгән.

Бу җитешсезлекләр ВКП(б) райкомының коммунистларны тәрбияләү мәсьәләсе белән аз шөгыльләнүен һәм үз карарларының үтәлешен җитәрлек дәрәҗәдә тикшермәвен күрсәтәләр. Райком инструкторлары Бутрев, Васильев һәм Минаев иптәшләр башлангыч оешмаларга баргач, төп игътибарны хуҗалык эшләренә генә юнәлдереп, политик-тәрбия мәсьәләләре белән тиешенчә кызыксынмаганнар.

Отчет-сайлау җыелышларында коммунистлар райком вәкилләре алдына партия эшләрен юлга салуда башлангыч оешмаларга ярдәм итү турында урынлы таләпләр куялар. (ТатТАСС).

Күңелсез фактлар

Баулы районының Ключево авыл советы коммунистларының отчет-сайлау җыелышы тәмам булды. Партоешма секретаре иптәш Подаваловның отчет доклады буенча фикер алышулар бик җанлы барды. Чыгып сөйләүчеләр партия оешмасының җитешсезлекләрен каты тәнкыйть уты астына алдылар. Партия оешмасы колхозларга начар җитәкчелек иткән, оешма стахановчы колхозчылар хисабына бик аз үскән. Отчет чоры эчендә партия сафына хатын-кызлардан бер кеше дә кабул ителмәгән. Яш коммунистларны партия эшенә өйрәтү, аларны политик яктан чыныктыру буенча һичбер эш алып барылмаган.

Җыелыш оешма секретаренең эшен канәгатьләнмәслек дип тапты.

Яшрен тавыш бирү тәртибендә оешма секретаре итеп тулы булмаган урта мәктәп директоры иптәш Астафьев сайланды.

(ТатТАСС).

АРАКЧИНО ЗАТОНЫНДА

Аракчино затоны җитәкчеләре 40 нчы ел навигациясенә ныклап хәзерләнү турында күп сөйләделәр инде. Ләкин эшкә килгәндә алар үзләренең вәгъдәләрен үтәмиләр. Судноларга ремонт ясау планы 10 нчы февральгә бары 59 процент кына үтәлде.

Механика цехында токарьлар, слесарьлар, тимерчеләр, котельщиклар җитешми. Цехны төсле металл белән тәэмин итү эше дә тирән өзеклектә. Югары Волга пароходчылыгы цехны тиешле материаллар белән тәэмин итү өчен практик чаралар күрми.

Производство командирлары, инженер-техник работниклар стахановчылык хәрәкәтенә йомшак җитәкчелек итәләр. Күп станокта эшләүчеләрнең уңышлы тәҗрибәләре башкаларга күчерелми. Иптәш Медведев ремонт башланганнан бирле ике станокта эшли. Ләкин аның тәҗрибәсен өйрәнү турында затон җитәкчеләренең әлегә кадәр бер төрле дә чара күргәннәре юк. Яисә стахановчы иптәш Чнаевны алып карыйк. Ул нормасын системалы рәвештә 180—200 процент итеп үти. Бу уңышка аның ничек ирешкәнлеге турында кызыксынучы юк.

Затонда төрле товар төялгән 36 баржа бар. Бу баржаларга ремонт ясау өчен 20 мең эш сәгате таләп ителә. Баржаларның үз вактында бушатылмаулары ремонт планының вактында үтәлүенә бик зур комачаулык итә. Үзләренең йөкләрен ташымаучы оешмалардан мехкомбинат, жиркомбинат һәм Гортопны күрсәтергә кирәк. Алар үзләренең йөкләрен 6 көн срок эчендә алырга тиешләр иде. Фактта исә, бу эш айлар буенча сузылып килә.

1940 нчы елның навигациясенә алдан ныклы хәзерлек—бөтен навигациянең уңышлы баруын хәл итә. Аракчино затоны җитәкчеләре һәм инженер-техник работниклары моны исләрендә нык тотарга тиешләр.

Ф. Исхаков.

ЯҢА ЙӨКЛӘМӘЛӘР АЛДЫЛАР

3 нче номерлы фанера заводының утиль цехы коллективы республикабызның XX еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен көрәшә. Бу уңай белән цехның бригадалары һәм сменалары арасында социалистик ярыш договорлары яңартып төзелделәр.

Цехның мебельчеләр бүлеге коллективы 1940 нчы елның ярты еллык планын 15 нче июньгә үтәргә булды һәм шул ук цехның „Хәбәрчеләр“ сменасын социалистик ярышка чакырды.

Зинин, Федотов, Муллин, Бабыков, Морозов һ. б. иптәшләр алган йөкләмәләрен намус белән үтиләр. Норма үтәлешен 235—335 проценттан киметмиләр. Алар эшләгән продукциянең сыйфаты да яхшы.

И. Фәйзуллин.

ТАТАРСТАН КОЛХОЗЛАРЫНДА

ТӘКӘНЕШТӘ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕКТӘ АШЫКМЫЙЛАР

Тәкәнеш районында язгы чәчүгә хәзерлек һич тә канәгатьләнерлек түгел. Район буенча кар тоту планы 1 нче февральгә 66 процент, көл җыю 35, кош тизәге җыю 27, компос ашлама хәзерләү планы 44 процент кына үтәлгән. „Беренче Май“ колхозында (председателе иптәш Мельников) басуга 6.500 урнына бары 600 йөк, „Искра“ колхозында (председателе иптәш Кормильцев) 300 урнына бары 250 йөк тирес чыгарылган.

Күп кенә колхозларда орлыкларны чәчүгә хәзерләү бик акрын бара. Районның орлык лабораториясе тарафыннан әлегә бары 24 мең центнер чәчүлек орлыкка анализ ясалган (план 39.550 центнер). Анализ ясалган орлыкларның 7.500 центнеры кондициягә җиткерелмәгән дип табылган. Анализ ясау өчен шушы вакытка кадәр 18 колхозның бер генә культура буенча да орлык үрнәкләре китергәннәре юк.

Колхозларда агрозоотехника укулары юлга салынмаган. Стахановчылык мәктәпләренең күбесе эшләми. МТС ның баш агрономы иптәш Рәхимев, участкы агрономы иптәш Бакеев, зоотехник иптәш Кадырова беркетелгән мәктәпләренә бер генә тапкыр да барганнары юк.

Һ. Шаһиев.

Колхозларда стахановчылык мәктәпләре

Чепья районында 11 урында стахановчылык мәктәпләре оештырылды. Бу мәктәпләрдә 243 колхозчы укый. 60 сәгатьлек программаның 38 сәгате агротехниканы өйрәнү турында.

Колхозчылар дәресләргә актив катнашалар. „Крестьянская газета“ колхозында оештырылган мәктәптә 35 колхозчы укый. Бу мәктәптә район җир бүлегенең баш агрономы иптәш Гаврилов 12 сәгать дәрес үткәрде.

Башка колхозларда оештырылган мәктәпләрдә дә укулар яхшы бара.

Х. Галләмев.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә хәзерлек

Кандидатлар билгеләү акрын бара

ӘЛМӘТ, 16 февраль. (Телефон буенча, үз хәбәрчебездән). 1937—38—39 нчы елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 12,5 центнер уңыш алган „Сабанчы“ колхозы 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашуга кандидат итеп билгеләнде. Аннан соң район советы башкарма комитеты алдынгы колхозчылардан, тракторчылардан күргәзмәгә катнашуны сорап язган 14 гаризаны карады һәм аларны авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашу өчен лаеклы кандидатлар дип тапты. Районның күп кенә колхозлары һәм алдынгылары күргәзмәгә катнашу өчен зур дәрт белән хәзерләнәләр.

Ләкин район советы башкарма комитеты һәм район җир бүлеге авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә кандидатлар сайлап алу, документлар оформить итү турында ашыкмыйлар әле. МТС дирекциясе дә күргәзмәгә кандидат итеп тракторчыларны күрсәтү белән генә чикләнә. Ул, үзе хезмәт күрсәтә торган колхозлар һәм авыл хуҗалыгы алдынгылары турында бөтенләй кайгыртмый.

Үткән елны районның 19 колхозы һәм 50 дән артык авыл хуҗалыгы алдынгылары күргәзмәдә катнаштылар. Быел күргәзмәгә катнашырлык колхозлар үткән елга караганда күбрәк. Тик аларны сайлап алу эшенә оператив җитәкчелек итәргә генә кирәк.

З. Салахеттинов.

ИКЕ ТҮРӘНЕ АПТЫРАТКАН РОЗА БЕЛӘН АБДРАХМАН

Роза Фәтхуллина—Абдрахман Әхметшинның иптәше. Абдрахман—Розаның иптәше. Эш анда түгел, гади генә итеп әйткәндә, алар ирле-хатынлы, яш кешеләр. Икесе дә белгеч. Икесе дә авылга китәргә булганнар. Әгәр дә эш шома гына үткән булса, Роза зоотехник булып, Абдрахман аптека работнигы булып әллә кайчан районда эшләрләр иде инде.

Ләкин аларның икесен бер районга җибәрү мәсьәләсе Татнаркомзем белән Татаптекоуправление алдында хәл ителә алмаслык бер „проблема“ булып баскан. Жир эшләре халык комиссары Чернов иптәшнең кадрлар буенча ярдәмчесе Корнилов һәм Аптекоуправление управляющие иптәш Аникинның урынбасары Фудин бу турыда ике атнадан бирле сөйләшү алып баралар. Ышанычлы мәгълүматларга караганда, сөйләшүләр бик бюрократик, җансызлык атмосферасында дәвам итсә кирәк.

Ике белгечне бер районга җибәрүнең очына чыга алмаган бу ике түрә хәзер мораль укырга керешкәннәр.

Фудин, иптәш Әхметшинга:

— Син, нинди ул хатыныңнан аерыла алмаган кеше. Тот та Чирмешәнгә кит, ди.

Иптәш Фәтхуллинага:

— Тәкәнешкә бара тор кирәк булса ирең артыныннан барыр, эзләп табар әле,— ди Корнилов.

Сөйләшүләрнең нәтиҗәсе әлегә өнә шул. Бюрократлар тудырган язмыш буенча, ирле-хатынлы кешеләрнең „берсе—магрибтә, икенчесе—мәшрыйктә“ булырга тиеш.

Производствога китәргә ашкынып торган кешеләргә моннан да артык көләп карау булырга мөмкинме?

Шундый караш аркасында Фәтхуллина һәм Әхметшин иптәшләр ике юл чатында калганнар. Китү мәсьәләләре хәл ителмәү аркасында алар 10 көннән бирле эшсез йөриләр. Наркомзем белән Татаптекоуправление бусагасын таптап йөрергә мәҗбүр булалар...

Ф. Балыкчы.

„Спартак“ җәмгыяте катогында (Казан) хоккей уены буенча тренировка вакты. И. Галиев фотосы.

МОПРНЫҢ ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

15—17 нче февральдә Казанда МОПР ның Татарстан өлкә конференциясе булып үтте. Конференциядә 126 делегат катнашты. МОПР Өлкә Комитеты председателе иптәш Малков отчет докладын ясады. Доклад буенча фикер алышуларда 20 кеше катнашты.

Аннары конференция халыкара хәл турында иптәш Тимофеевның докладын тыңлады.

Соңгы елларда Татарстанның МОПР оешмалары шактый зур уңышларга ирештеләр. Хәзерге көндә Казанда һәм районнарда МОПР ның 2.744 ячейкасында 135.333 член исәпләнә. Шулардан 95 ячейка МОПР ның отчет-сайлау кампаниясе барган вакытта төзелде һәм бу ячейкаларга 16.740 член кабул ителде. МОПР оешмалары революция көрәшчеләренә ярдәм фондына 1938 нче елның ноябреннән алып конференция чакырылган көнгә кадәр 406.876 сум акча туплап җибәрделәр.

Конференция МОПР Өлкә Комитетының эшен канәгатьләнерлек дип тапты һәм МОПР оешмаларының эшен тагын да үстерү өчен күп кенә практик чаралар билгеләде.

МОПР Өлкә Комитеты пленумы составына 31 кеше, МОПР Өлкә Комитеты председателе итеп иптәш Малков, аның урынбасары итеп иптәш Сидоров сайланды.

МОПР ның алдынгы оешмаларыннан Ворошилов һәм Тымытык район комитетлары күчмә кызыл байрак белән бүләкләнде. МОПР активистларыннан 17 кеше „МОПР активисты“ значогы белән, 21 кеше СССР МОПР ының почет грамотасы белән, 30 кеше көтепханә белән бүләкләнде.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫНДА

Казан Дәүләт циркы Кызыл Армия частьләренә шефлык тәртибендә системалы рәвештә культура хезмәте күрсәтеп килә. Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының данлыклы бәйрәме уңае белән 20 нче февральдә кич 6 сәгатьтә һәм 23 нче февральдә көндез кызыл армеецлар һәм начальниклар составы өчен махсус спектакльләр дә куела. Спектакльләрдә циркның иң яхшы көчләре катнашачак.

КЫШКЫ АУ ТӘМАМ БУЛДЫ

Җәнлекләрне кыш көне аулау срогы 15 нче февральдә тәмам булды. Татнаркомземның Дәүләт аучылык инспекциясе бары тик төлкеләрне генә 25 нче февральгә кадәр ауларга рөхсәт итте. Ләкин аларны да этләр алып чыкмыйча гына ауларга мөмкин.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Квартирадан урлаучылар. Күптән түгел генә ябылудан чыккан Ш. Т. Гайсин һәм П. Г. Тарасенко дигән җинаятьчеләр янадан урлауга керешкәннәр. Алар Волков урамындагы 47 нче йортта торучы Венгеровская һәм башка гражданнарның квартираларына йозак ватып кереп, 18.000 сумлык төрле киемнәр урлаганнар. Җинаятьчеләр бу әйберләрне күтәреп барган вакытта, Островский урамында милиционерлар тарафыннан тотылганнар.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕ ЛЕНИН ҺӘМ СТАЛИН ТӘРБИЯЛӘП ҮСТЕРДЕ *)

Полковник Н. БУШМАНОВ

1919 нчы елның язына Антанта империалистлары Совет республикасына каршы беренче поход оештырдылар.

Ленин—Сталин партиясе бөтен совет халкын Ватан сугышына күтәрде, үзенең ун меңнәрчә членнарын Кызыл Армиягә җибәрде. Лениннең һәм Сталинның, аларның турылыклы көрәштәшләренең — пролетар полководецларның—Фрунзенең һәм Ворошиловның турыдан-туры җитәкчелегендә Кызыл Армия, Колчакны һәм Юденичны тар-мар итеп, Антантаның беренче походын бәреп ташлады.

1919 нчы елның җәендә Антанта икенче поход оештыра башлады һәм көзгә таба ак гвардеецларны яңадан Совет властена каршы юнәлдерде. Бу юлы төп ударны Деникин ясады. Деникинны тар-мар итүне оештыру эшен партия иптәш Сталинга тапшырды. Троцкийның хиянәтчел планын иптәш Сталин кире какты һәм Деникинны тар-мар итү буенча үзенең даһи планын төзеде. Бу планны тормышка ашыру өчен көчләрне оештырып, иптәш Сталин атлы кызыл гаскәргә аеруча әһәмият бирде. Гражданнар сугышында атлылар массасының роленә беренче буларак югары бәя биреп, ул Беренче Атлы Армияне төзеде. Армия командующие итеп иптәш С. М. Буденный, Армия Реввоенсоветы членнары итеп Ворошилов һәм Щаденко иптәшләр билгеләнделәр.

Фронтның башка армияләре белән бергә хәрәкәт итеп, атлы армия Деникин гаскәрләрен тар-мар итте. Петроград янында Кызыл Армия Юденич армиясен икенче тапкыр җимерде. Көнчыгыш фронтында колчакчылар тар-мар ителде.

Ләкин тын алу бик кыска вакытка гына булып чыкты. Ак паннар Польшасы һәм Врангель гаскәрләрен коралландырып, Антанта Совет республикасына каршы өченче поход башлый.

Партия үзенең игътибарын фронтка күчерә һәм Антантаның өченче походын тар-мар итүне оештыра. Иптәш Сталин җитәкчелегендә көньяк-көнбатыш фронты гаскәрләре Украинадагы ак полякларга җимергеч удар ясыйлар. Беренче Атлы Армиянең ак поляклар фронтын кисеп керүе һәм поляк армияләренең тылларына ясалган рейд бөтен Польша фронтын тетрәтә. Бу фронт Варшава һәм Львов стеналары янына кысырыклана. Антантаның киң ярдәм итүе һәм Иуда—Троцкийның хиянәтчел директивалары ул вакытта ак полякларны бөтенләй тар-мар ителүдән коткара.

Врангельне тар-мар итүне оештырып, иптәш Сталин Икенче Атлы Армия һәм беренче авиоберләшмә төзи. Көньяк фронтның талантлы пролетар полководец М. В. Фрунзе җитәкчелегендәге кызыл армияләре, иптәш Сталинның оператив планы идеяләрен тормышка ашырып, Төньяк Таврияда Врангель гаскәрләрен тар-мар иттеләр, акларның перекоп һәм Чонгар бугазларындагы ныгытмаларына штурм ясап, аларны алдылар.

Гражданнар сугышы тәмам була. Кызыл Армия тыныч хезмәткә күчә. Ләкин капиталистик чолганыш Совет республикасы өчен даими куркыныч булып тора.

Яңа шартларда армияне тагын да яхшырту һәм үзгәртеп кору чоры башланды. Халыкның явыз дошманы Троцкий армиянең үсүенә һәр төрле юллар белән комачаулык итә. Партия Үзәк Комитеты Троцкийны хәрби эштән ала. Кызыл Армияне ныгыту турында карар кабул итә, кораллы көчләр җитәкчелегенә М. В. Фрунзене һәм К. Е. Ворошиловны куя. М. В. Фрунзене республика Реввоенсоветы председателе итеп, ә К. Е. Ворошиловны Совет члены итеп билгеләү белән социализм иленең кораллы көчләре тамырдан яңа баштан корыла башлады.

1924 нче елның 21 нче январенда хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы В. И. Ленин үлде. Аның якын көрәштәше һәм дусты И. В. Сталин юлбашчының һәм остазның васыятьләрен азагынача үтәргә дип партия һәм халык исеменнән бөек ант бирде.

Сталинчыл бишьеллыкларны үтәү нәтиҗәсендә Кызыл Армия дөньяда иң яхшы, яңа сугыш техникасы алды.

Кызыл Армиянең сугышчан тәҗрибәсенә йомгак ясап, иптәш Сталин аны сугыш сәнгатенең иң алдынгы теориясе белән коралландыра. Армиянең стратегиясе һәм тактикасы турындагы таглимат, тыл турындагы, идарә принциплары турындагы, һөҗүм законнары турындагы таглимат совет халкының куәтле армиясенең стратегия һәм тактикасының нигез ташы булып торалар.

Кызыл Армияне дөньяда иң яхшы техника белән коралландырып, иптәш Сталин армия өчен техниканы бик яхшы үзләштергән большевик кадрлар хәзерләү бурычын куйды. 1935 нче елны хәрби академиклар чыгарылышында ул болай диде:

„Элек без „техника барсын да хәл итә“ дип әйтә идек. Бу лозунг безгә шул яктан ярдәм итте ки, без техника өлкәсендә ачлыкны бетердек һәм кешеләребезне беренче класслы техника белән коралландыру өчен эшнең барлык тармакларында иң киң техника базасы тудырдык. Бу бик яхшы. Ләкин бу җитәрлек булудан ерак һәм ерак әле. Техниканы хәрәкәткә китерү һәм аны төбенә кадәр файдалану өчен, техниканы үзләштергән кешеләр кирәк, бу техниканы үзләштерергә һәм осталыкның бөтен кагыйдәләре буенча файдаланырга сәләтле кадрлар кирәк. Техниканы үзләштергән кешеләр булмаганда, техника,—җансыз. Башында техниканы үзләштергән кешеләр торган техника могҗизалар бирә ала һәм бирергә тиеш“.

Ленин—Сталин партиясе Кызыл Армия өчен сугыш техникасын бик яхшы үзләштергән, культуралы, партиягә һәм халыкка чиксез бирелгән сугышчылар, командирлар һәм политработниклар кадрларын тәрбияләп үстерде. Кызыл Армия дөньяда иң яхшы, иң көчле армия булып әверелде.

Икенче империалистик сугыш башланып киткәнлектән һәм Ватаныбызга каршы турыдан-туры сугыш авантюралары куркынычы туганлыктан Кызыл Армияне оештыру ягыннан яңадан төзү кирәк булды. Иптәш Сталин инициативасы белән бөтен Кызыл Армия кадровый системага күчерелә. Белгеч сугышчылар катлаулы сугыш техникасын тагын да яхшырак үзләштерсеннәр өчен аларның хезмәт сроклары озайтыла. Мәктәпләрдә башлангыч хәрби белем дәресе кертелә. Мәҗбүри гаскәри хезмәт турындагы яңа закон Кызыл Армиянең үсешендә яңа этапка нигез сала.

Безнең илебездә армия һәм халык—бердәм. Кызыл Армия—халыкның иң яхшы өлеше, аның кадерле баласы. Кызыл Армиянең геройлары—алар бөтен халык геройлары. Кызыл Армия гаскәрләренең һәм Хәрби Диңгез Флотының партия һәм хөкүмәт заданиеләрен үтәве һәр вакыт бөтен халыкның гаять зур сугышчан күтәренкелеге белән бергә бара. Бу, Кызыл Армиянең тылы бик нык булуны тәэмин итә, аны җимерелмәслек көчкә әйләндерә. Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты—алар тик чиксез күп булган, бөек совет халкы дип исемләнә торган армиябезнең алдынгы отрядлары, алдынгы постлары гына. Андый армия җиңелмәслек булды, булып тора һәм мәңгегә булыр.

*) Башы „Кызыл Татарстан“ның 20 нче февраль номерында.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

БҮГЕН ТЕАТР ҺӘМ КИНОЛАРДА:

Зур Драма театры—Бакчалар чәчәк ата. Талон 106.

Дәүләт циркы—яңартылган программа буенча зур цирк уены.

„Электро“—Дүртенче перископ. „Уннон“—Дуслар. „Кызыл Йолдыз“—Чапаев. „Колхозник“—Соңгы төн. „Чатки“—Иуда. „Пионер“—Патриот. „Рот Фронт“—Степан Разин. Культура Сарае—Тайга еракларында.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 725 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 688.